КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 апрель г.Казань № 364

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 21 июль, 521 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 950 нче; 2015 ел, 6 май, 329 нчы; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2015 ел, 1 декабрь, 910 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 383 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 980 нче; 2017 ел, 27 февраль, 117 нче; 2018 ел, 5 май, 326 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 866 нчы; 2019 ел, 27 июль, 628 нче; 2020 ел, 8 июнь, 472 нче; 2020 ел, 12 ноябрь, 1013 нче, 2021 ел, 4 май, 304 нче, 2021 ел, 9 октябрь, 966 нчы, 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары

2014 – 2024 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 24 390 309,0 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:
билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 9 342 236,8 мең сум;
Татарстан Республикасы бюджеты акчасы - 12 301 560,9 мең сум;
күздә тотыла торган җирле бюджетлар акчасы – 2 746 511,3 мең сум, шул исәптән:
I этап – 8 051 670,7 мең сум, шул исәптән:
билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 787 237,4 мең сум;
Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 5 735 086,9 мең сум;
җирле бюджетлар акчасы – 1 529 346,4 мең сум, шул исәптән:

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | Барлыгы акча | Еллар буенча финанслау күләмнәре (I этап) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Федераль бюджет | 787 237,4 | 109 110,2 | 72 825,8 | 89 282,5 | 348 873,2 | 70 035,4 | 97 110,3 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 5 735 086,9 | 1 216 164,0 | 697 012,1 | 883 611,8 | 1 194 626,9 | 742 237,7 | 1 001 434,4 |
| Җирле бюджетлар | 1 529 346,4 | 307 600,0 | 290 707,0 | 230 392,0 | 198 628,2 | 274 544,9 | 227 474,3 |
| Барысы | 8 051 670,7 | 1 632 874,2 | 1 060 544,9 | 1 203 286,3 | 1 742 128,3 | 1 086 818,0 | 1 326 019,0 |

II этап - 16 338 638,3 мең сум*, шул исәптән:
билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 8 554 999,4 мең сум;
Татарстан Республикасы бюджеты акчасы - 6 566 474,0 мең сум;
күздә тотыла торган җирле бюджетлар акчасы – 1 217 164,9 мең сум, шул исәптән:

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | Барлыгы акча | Еллар буенча финанслау күләмнәре (II этап) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Федераль бюджет | 8 554 999,4 | 1 347 012,0 | 998 611,8 | 3 099 598,4 | 1 536 421,4 | 1 573 355,8 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 6 566 474,0 | 1 752 734,3 | 1 766 415,3 | 1 362 480,7 | 857 475,0 | 827 368,7 |
| Җирле бюджетлар | 1 217 164,9 | 205 296,9 | 252 934,0 | 252 978,0 | 252 978,0 | 252 978,0 |
| Барысы | 16 338 638,3 | 3 305 043,2 | 3 017 961,1 | 4 715 057,1 | 2 646 874,4 | 2 653 702,5 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;

«Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тулы күләмдә тормышка ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>I этап (2014 – 2019 еллар):<br>2014 елга җирлекләрне яшелләндерү дәрәҗәсен 27 процентка кадәр арттырырга;<br>2019 елга:<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми санынннан каты коммуналь калдыкларны аерым җыю һәм эшкәртү (сортларга аеру) барышында алынган икенчел ресурслар өлешен 20 процентка кадәр арттырырга;<br>биологик калдыклар җыю һәм алып китү буенча 8 данә контейнер сатып алырга;<br>Татарстан Республикасы территориясендәге Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары акваторияләре чикләрендә суга баткан 90 берәмлек йөзү чарасын тикшерергә;<br>җыелган экологик зыянның 5 объектын юк итәргә;<br>ел саен 1 мең нөсхә тиражы белән «Георесурсы» журналы чыгарылышлары саны – 4 чыгарылыш;<br>Түбән Кама муниципаль районының торак пунктларында төзелгән биологик чистарту корылмалары саны – 3 берәмлек;<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабына ел саен кертелгән төрләр саны – 1 берәмлек;<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабына ел саен кертелгән, сирәк булуның иң түбән категориясенә күчерелгән төрләр саны – 1 берәмлек;<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабыннан ел саен чыгарылган төрләр саны – 1 берәмлек;<br>махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча ел саен чыга торган басмалар саны – кимендә 1 данә;<br>махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча басмалар санын 15 данәгә кадәр җиткерергә;<br>әйләнә-тирә мохит торышы турындагы дөрес мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеге булган Татарстан Республикасы халкы өлешен 0,18 процентка кадәр арттырырга;<br>2018 – 2019 елларга Россия Федерациясе субъектларында Инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту чаралары планының («юл картасының») билгеләнгән вакытларда үтәлгән чаралары өлешен 100 процент тәэмин итәргә;<br>төбәк дәүләт экология күзәтчелеге нәтиҗәлелеген 3,8 мең сум күләмендә тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау, |

| | |
|---|---|
| | табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә яңа төзелгән социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары саны – 10 берәмлек;<br>Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә ремонт ясалган социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары саны – 3 берәмлек;<br>II этап (2020 – 2024 еллар):<br>2024 елга:<br>әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүнең территориаль системасы урнаштырылган муниципаль районнар (шәһәр округлары) саны – 40 берәмлек;<br>атмосфера һавасы пычрануның җыелма исәп-хисапларына кертелгән Татарстан Республикасының эре шәһәрләре саны – 6 берәмлек;<br>әйләнә-тирә мохит сыйфаты буенча эшләнгән һәм гамәлгә кертелгән төбәк нормативлары саны – 40 берәмлек;<br>республикада яшәүчеләрнең гомуми санынннан табигатьне саклау, экология-агарту чараларында катнашучы халык өлешен 35,4 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасы халкының гомуми санынннан каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителгән халык өлешен 90 процентка кадәр арттырырга;<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында күмү өчен җибәрелгән, шул исәптән эшкәртелгән (сортларга аерылган) каты коммуналь калдыклар өлешен 99,1 процентка кадәр арттырырга;<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында эшкәртүгә (сортларга аеруга) җибәрелгән каты коммуналь калдыклар өлешен 40 процентка кадәр арттырырга;<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында каты коммуналь калдыкларны аерып җыю һәм эшкәртү (сортларга аеру) нәтиҗәсендә аерылган һәм утилизацияләүгә җибәрелгән калдыклар өлешен 0,9 процентка кадәр арттырырга;<br>каты коммуналь калдыкларны аерым туплау һәм җыю өчен җиһазландырылган контейнер мәйданчыклары өлешен 40 процентка кадәр арттырырга;<br>каты коммуналь калдыкларны заманча күмү объектларында урнаштырылган каты коммуналь калдыклар өлешен 100 процентка кадәр арттырырга;<br>җыелган экологик зыянның иң куркыныч 2 объектын юк итәргә; |

| | |
|---|---|
| | җыелган экологик зыянның Идел елгасына куркыныч яный торган 2 объектын бетерергә;<br>куркыныч экзоген геологик процесслар мониторингы белән колачланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары санының куркыныч экзоген геологик процессларның тискәре йогынтысына дучар булган Татарстан Республикасы муниципаль районнары санына карата нисбәтен 39 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>геологик мохит мониторингы белән колачланган территория мәйданының Татарстан Республикасы территориясенең гомуми мәйданына карата нисбәтен 48,2 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>җир асты суларының расланган запаслары һәм аларның фаразланган ресурслары нисбәтен 43 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>су алу корылмаларының гомуми санында суны исәпкә алу системалары белән җиһазландырылган су алу корылмалары өлешен 96 процентка кадәр арттырырга;<br>елга үзәннәренең чистартылган участоклары озынлыгы – 21,3 км;<br>Татарстан Республикасының гомуми мәйданында барлык дәрәҗәләрдәге махсус саклана торган табигать территорияләре биләгән Татарстан Республикасы мәйданы өлешен 6,8 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасының махсус саклана торган табигать территорияләрендә ачыкланган һәм кисәтелгән бозулар саны – ел саен кимендә 690 берәмлек;<br>Татарстан Республикасы территориясендә яши торган аучылык ресурслары төрләренең гомуми санында аучылык ресурслары саны мониторингы алып барыла торган әлеге ресурслар төрләре өлешен 100 процентка кадәр арттырырга;<br>билгеләнгән бозулар фактларының гомуми санында федераль дәүләт аучылык контроле (күзәтчелеге) өлкәсендә ачыкланган һәм җаваплылыкка тарту турында карарлар чыгарылган бозулар өлешен 90 процентка кадәр арттырырга;<br>стационар чыганаклардан чыга торган пычраткыч матдәләрнең гомуми күләмендә атмосфера һавасын пычрата торган матдәләрнең тотылган һәм зарарсызландырылган өлешен 61 процентка кадәр арттырырга;<br>тикшерелгән автомобильләрнең гомуми санында эшләп чыгарылган газларында пычраткыч матдәләр күп булган автотранспорт чаралары өлешен 6,8 процентка кадәр киметергә;<br>су чыгаруның гомуми күләмендә агып төшә торган суларның |

| | |
|---|---|
| | пычрак (чистартылмаган) өлешен 11,1 процентка кадәр киметергә;<br>рекультивацияләнә торган җирләр өлешен 46 процентка кадәр арттырырга;<br>агып төшә торган суларның гомуми күләмендә агып төшә торган суларның норматив чистартылган өлешен 19,0 процентка кадәр арттырырга;<br>табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә ачыкланган бозулар санынннан бетерелгән бозулар өлешен кимендә 96 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә (В.2.5 төркеме күрсәткече);<br>салынган штрафлардан түләтелгән акча өлешен кимендә 70 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә (В.3.1.37 төркеме күрсәткече);<br>административ җәзаларның гомуми санында кисәтүләр өлешен кимендә 10 процент тәэмин итәргә (В.3.2.9 күрсәткече);<br>Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгаруның лицензиясез фактлары санын 53 берәмлеккә кадәр киметүне тәэмин итәргә (А.3 төркеме күрсәткече);<br>бирелгән лицензияләр санының файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы алу турындагы гаризаларның карап тикшерелгән санына карата нисбәтен 96 процентка кадәр тәэмин итәргә»; |

Программаның II бүлегендәге «Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасы чаралары» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасы чаралары

Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычрату дәрәҗәсен киметү, икенчел чималдан матди ресурслар җитештерүне үстерү өчен технологик циклга җәлеп ителә торган калдыклар күләмнәрен арттыру максатларында «Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасында түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

«Татарстан Республикасының экологик картасы» геомәгълүмат системасының «Калдыклар ташу өчен билгеләнгән транспорт чаралары мониторингы» ярдәмче системасын эшләү;

икенчел ресурсларны аерым җыю мәгариф учреждениеләрендә укучылар

тарафыннан җыю буенча акцияләр уздыру;

ККК полигоннарын һәм чүп сортлаштыру станцияләрен төзү;

Татарстан Республикасы мәгариф учреждениеләре өчен чүп-чарны аерым җыю өчен урналар әзерләү һәм җибәрү;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территориясендә каты коммуналь (көнкүреш) калдыклар һәм башка куллану калдыклары белән эш итү системасын эшләү;

туклану элементларын (батареяларны) утильләштерү технологиясен эшләү;

калдыклар, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схема проектын эшләп бетерү максатларында, республикада гамәлдә булган каты коммуналь калдыклар полигоннарының калган ресурсларын инструментлар белән үлчәп чыгу;

Татарстан Республикасының җитештерү һәм куллану калдыкларының төбәк кадастрын алып бару мәгълүмат системасын булдыру;

калдыклар белән эш итү өлкәсендә, шул исәптән Татарстан Республикасы ККК белән эш итү өлкәсендә территориаль схеманың электрон моделен булдыру өчен «Калдыклар белән эш итү» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» (алга таба - «Калдыклар белән эшитү» АМС ПТИ) программа белән тәэмин итүне эшләү;

калдыкларны вакытлыча туплау өчен савытлар әзерләү һәм аларны китерү;

куркыныч каты коммуналь калдыкларны җыю өчен зур сыйдырышлы махсус контейнерлар сатып алу;

ККК полигоннарын һәм чүп сортлаштыру станцияләрен төзү;

ККК белән эш итү буенча муниципаль тармакара коммуналь комплекслар төзү;

муниципаль районнарга хезмәт күрсәтү өчен биологик калдыклар җыю һәм чыгару буенча контейнерлар сатып алу.

әйләнә-тирә мохиткә тупланган экологик зыян объектларын бетерү;

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын оештыру.»;

«Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге хезмәтләре эшчәнлеген координацияләү» ярдәмче программасы чаралары» бүлекчәсендә:

беренче абзацта «күзәтчелек» сүзен «контроль (күзәтчелек) һәм дәүләт геологик контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «күзәтчелек» сүзен «контроль (күзәтчелек) һәм дәүләт геологик контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «күзәтчелек» сүзен «контроль (күзәтчелек)» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2014 – 2024 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 24 390 309,0 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 9 342 236,8 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы - 12 301 560,9 мең сум;

күздә тотыла торган җирле бюджетлар акчасы – 2 746 511,3 мең сум, шул исәптән:

I этап – 8 051 670,7 мең сум, шул исәптән:

билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 787 237,4 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 5 735 086,9 мең сум;

җирле бюджетлар акчасы – 1 529 346,4 мең сум, шул исәптән:

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | Барлыгы акча | Еллар буенча финанслау күләмнәре (I этап) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Федераль бюджет | 787 237,4 | 109 110,2 | 72 825,8 | 89 282,5 | 348 873,2 | 70 035,4 | 97 110,3 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 5 735 086,9 | 1 216 164,0 | 697 012,1 | 883 611,8 | 1 194 626,9 | 742 237,7 | 1 001 434,4 |
| Җирле бюджетлар | 1 529 346,4 | 307 600,0 | 290 707,0 | 230 392,0 | 198 628,2 | 274 544,9 | 227 474,3 |
| Барысы | 8 051 670,7 | 1 632 874,2 | 1 060 544,9 | 1 203 286,3 | 1 742 128,3 | 1 086 818,0 | 1 326 019,0 |

II этап - 16 338 638,3 мең сум*, шул исәптән:

билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы – 8 554 999,4 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы - 6 566 474,0 мең сум;

күздә тотыла торган җирле бюджетлар акчасы – 1 217 164,9 мең сум, шул исәптән:

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | Барлыгы акча | Еллар буенча финанслау күләмнәре (II этап) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Федераль бюджет | 8 554 999,4 | 1 347 012,0 | 998 611,8 | 3 099 598,4 | 1 536 421,4 | 1 573 355,8 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 6 566 474,0 | 1 752 734,3 | 1 766 415,3 | 1 362 470,7 | 857 475,0 | 827 368,7 |
| Җирле бюджетлар | 1 217 164,9 | 205 296,9 | 252 934,0 | 252 978,0 | 252 978,0 | 252 978,0 |
| Барысы | 16 338 638,3 | 3 305 043,2 | 3 017 961,1 | 4 715 057,1 | 2 646 874,4 | 2 653 702,5 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Ярдәмче программалар яктылыгында Программаны финанслау күләмнәре, финанслау чыганаклары һәм акча белән баш эш итүчеләр турындагы мәгълүмат Программага 2 нче кушымтада китерелә.»;

Программага 1, 2, 4 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

«Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохите сыйфатын җайга салу» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләме | 1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 826 719,3 мең сум* тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>I этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 563 519,6 мең сум, шулардан:<br>2014 елда – 240 035,3 мең сум;<br>2015 елда – 53 741,1 мең сум;<br>2016 елда – 68 298,5 мең сум;<br>2017 елда – 65 904,5 мең сум;<br>2018 елда – 76 961,6 мең сум;<br>2019 елда – 58 578,6 мең сум;<br>II этап – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 263 199,7 мең сум, шулардан:<br>2020 елда – 31 327,4 мең сум;<br>2021 елда - 78 024,1 мең сум;<br>2022 елда - 57 850,0 мең сум;<br>2023 елда – 47 999,1 мең сум;<br>2024 елда – 47 999,1 мең сум.<br>*Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; |

1 нче ярдәмче программаның I бүлегенең егерме икенче абзацында «күзәтчелек» сүзен «контроль (күзәтчелек) һәм дәүләт геологик контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 1 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 826 719,3 мең сум* тәшкил итәчәк, шул исәптән:

(мең сум)

| Еллар | Барлыгы акча | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|
| 2014 | 240 035,3 | 240 035,3 |
| 2015 | 53 741,1 | 53 741,1 |
| 2016 | 68 298,5 | 68 298,5 |
| 2017 | 65 904,5 | 65 904,5 |
| 2018 | 76 961,6 | 76 961,6 |
| 2019 | 58 578,6 | 58 578,6 |
| Барысы I этап | 563 519,6 | 563 519,6 |
| 2020 | 31 327,4 | 31 327,4 |
| 2021 | 78 024,1 | 78 024,1 |

| | | |
|---|---|---|
| 2022 | 57 850,0 | 57 850,0 |
| 2023 | 47 999,1 | 47 999,1 |
| 2024 | 47 999,1 | 47 999,1 |
| Барысы II этап | 263 199,7 | 263 199,7 |
| Барысы | 826 719,3 | 826 719,3 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

1 нче ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт идарәсе» ярдәмче программасында (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

2 нче ярдәмче программа паспортында:

«Еллар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәянв итәргә:

«Еллар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү күләме 9 753 986,8 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән 2 672 281,1 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 7 081 705,7 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы, шул исәптән:

(мең сум)

| Еллар | Барлыгы* | Федераль бюджет акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 164 187,8 | - | 164 187,8 |
| 2015 | 128 940,8 | - | 128 940,8 |
| 2016 | 26 902,2 | - | 26 902,2 |
| 2017 | 91 627,5 | 26 866,0 | 64 761,5 |
| 2018 | 91 059,8 | - | 91 059,8 |
| 2019 | 12 335,8 | - | 12 335,8 |
| Барысы I этап | 515 053,9 | 26 866,0 | 488 187,9 |
| 2020 | 1 113 805,9 | 718 084,2 | 395 721,7 |
| 2021 | 1 138 456,9 | 804 801,1 | 333 655,8 |
| 2022 | 3 501 782,9 | 2 793 659,9 | 708 123,0 |
| 2023 | 1 727 955,3 | 1 326 143,8 | 401 811,5 |
| 2024 | 1 756 931,9 | 1 412 150,7 | 344 781,2 |
| Барысы II этап | 9 238 932,9 | 7 054 839,7 | 2 184 093,2 |
| Барлыгы | 9 753 986,8 | 7 081 705,7 | 2 672 281,1 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;

«Еллар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тулы күләмдә гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>I этап (2014 – 2019 еллар):<br>2016 елга:<br>каты коммуналь калдыкларның санкцияләнмәгән һәм бетерелгән чүплекләре өлешен 95 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасы территориясендәге Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары акваторияләре чикләрендә суга баткан 90 йөзү чарасын тикшерергә;<br>2019 елга:<br>тупланган әйләнә-тирә мохиткә зыянның 3 объектын бетерергә;<br>II этап (2020 – 2024 еллар):<br>2020 елга:<br>«Чиста ил» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында тупланган экологик зыянның 2 аеруча куркыныч объектын бетерергә;<br>2024 елга:<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында күмү өчен җибәрелгән, шул исәптән эшкәртелгән (сортларга аерылган) каты коммуналь калдыклар өлешен 99,1 процентка кадәр арттырырга;<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында эшкәртүгә (сортларга аеруга) җибәрелгән каты коммуналь калдыклар өлешен 40 процентка кадәр арттырырга;<br>барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында каты коммуналь калдыкларны аерып җыю һәм эшкәртү (сортларга аеру) нәтиҗәсендә аерылган һәм утилизацияләүгә җибәрелгән калдыклар өлешен 0,9 процентка кадәр арттырырга;<br>каты коммуналь калдыкларны аерым җыюны гамәлгә ашыру өчен җиһазландырылган контейнер мәйданчыклары өлешен 40 процентка кадәр арттырырга;<br>каты коммуналь калдыкларны заманча күмү объектларында урнаштырылган каты коммуналь калдыклар өлешен 100 процентка кадәр арттырырга; |

| | |
|---|---|
| | «Чиста ил» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында шәһәр чикләрендә 3 санкцияләнмәгән чүплекне бетерергә;<br>үткәндәге экологик зыянның Идел елгасына куркыныч яный торган 2 объектын бетерергә»; |

2 нче ярдәмче программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. 2 нче ярдәмче программаның максаты, бурычлары, чаралары һәм максатларга ирешү һәм бурычларны хәл итү күрсәткечләре (индикаторлар)

2 нче ярдәмче программа түбәндәге төп максатларга ирешү өчен эшләнде: Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычрату дәрәҗәсен киметү, икенчел чималдан матди ресурслар җитештерүне үстерү өчен технологик циклга җәлеп ителә торган калдыклар күләмнәрен арттыру, кулланучыларны каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча үзәкләштерелгән коммуналь хезмәт күрсәтү белән һәр урында тәэмин итү.

2 нче ярдәмче программа чаралары түбәндәге төп бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

1. Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән идарә итүнең бердәм комплекслы системасын булдыру һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең гамәлдәге инфраструктурасын экологик, санитар-эпидемиологик иминлек һәм икътисадый нәтиҗәлелек таләпләре нигезендә, шул исәптән «Каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең комплекслы системасы» федераль проекты кысаларында модернизацияләү.

2. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш иткәндә тупланган экологик зыян объектларын бетерү.

3. «Чиста ил» федераль проекты кысаларында чараларны тормышка ашыру.

4. «Иделне савыктыру» федераль проекты кысаларында Идел елгасына куркыныч яный торган үткәндәге экологик зыян объектларын бетерү;

5. Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт исәбенә алу һәм тикшереп тору системасы белән идарә итү.

Беренче бурыч кысаларында түбәндәге чараларны үткәрү тәэмин ителәчәк:

«Татарстан Республикасының экологик картасы» геомәгълүмат системасының «Калдыклар ташу өчен билгеләнгән транспорт чаралары мониторингы» ярдәмче системасын эшләү;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территориясендә каты коммуналь калдыклар һәм башка куллану калдыклары белән эш итү системасын эшләү;

калдыклар, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схема проектын эшләп бетерү максатларында, республикада гамәлдә булган каты коммуналь калдыклар полигоннарының калган ресурсларын инструментлар белән үлчәп чыгу;

Татарстан Республикасының калдыклар, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схеманың электрон моделен булдыру;

куркыныч каты коммуналь калдыкларны җыю өчен зур сыйдырышлы махсус контейнерлар сатып алу;

муниципаль районнарга хезмәт күрсәтү өчен биологик калдыклар җыю һәм чыгару буенча контейнерлар сатып алу.

Беренче бурычны хәл итүнең төп күрсәткечләре түбәндәгеләр:

җитештерү һәм куллану процессында барлыкка килгән калдыкларның гомуми күләмендә файдаланылган, зарарсызландырылган калдыклар өлеше, процент;

ККК үзәкләштерелгән җыю системасына кертелгән Татарстан Республикасы торак пунктларының өлеше (ККК җыю һәм транспортировкалау буенча коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителгән), процент;

ККК белән эш итү буенча хезмәт күрсәтүләрне колачлаган халыкның өлеше, процент;

барлыкка килгән ККК гомуми санында эшкәртелгән ККК өлеше, процент;

барлыкка килгән ККК гомуми санында ККК җыю һәм эшкәртү (сортлаштыру) процессында барлыкка килгән икенчел ресурслар өлеше, процент;

барлыкка килгән ККК гомуми санында утильләштерелгән ККК өлеше, процент;

утильчималны (икенчел ресурсларны) кабул итүнең гамәлдәге пунктлары саны, данә;

барлыкка килгән ККК гомуми санында электр һәм (яисә) җылылык энергиясе генерациясе белән термик зарарсызландырылган ККК өлеше, процент;

ККК аерым туплауны гамәлгә ашыру өчен җиһазландырылган контейнер мәйданчыклары өлеше, процент;

барлыкка килгән ККК гомуми санында күмелгән ККК өлеше, процент;

барлыкка килгән ККК гомуми санында күмүгә җибәрелгән, шул исәптән эшкәртелгән (сортлаштырылган) КК өлеше, процент;

ККК заманча күмү объектларында урнаштырылган ККК өлеше, процент;

барлыкка килгән ККК гомуми массасында эшкәртүгә (сортлаштыруга) җибәрелгән ККК өлеше, процент;

барлыкка килгән ККК гомуми күләмендә утильләштерүгә җибәрелгән ККК өлеше, процент;

барлыкка килгән ККК гомуми массасында аерым туплау һәм эшкәртү (сортлаштыру) нәтиҗәсендә бүлеп бирелгән калдыкларның утильләштерүгә юнәлдерелгән өлеше, процент;

ККК эшкәртү һәм утильләштерү өчен җиһазлар импорты өлеше, процент;

эшләнгән электрон модельләр саны, данә;

биологик калдыкларны җыю һәм чыгару өчен сатып алынган контейнерлар саны, данә;

Икенче бурыч кысаларында әйләнә-тирә мохиткә тупланган экологик зыян салу объектларын бетерү чараларын тормышка ашыру, аеруча куркыныч пычраклар белән бозылган җирләрне, эксплуатацияләү срогы чыккан каты коммуналь калдыклар полигоннарын һәм чүплекләрен рекультивацияләү күздә тотыла.

Икенче бурычны хәл итүнең төп күрсәткечләре түбәндәгеләр:

каты көнкүреш калдыкларының рөхсәтсез юкка чыгарылган чүплекләре өлеше, процент;

тупланган экологик зыянның бетерелгән объектлары саны, данә;

Татарстан Республикасы территориясендә Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары акваториясендә урнашкан, суга баткан һәм тикшерелгән йөзү чаралары саны, берәмлек;

Өченче бурыч кысаларында «Экология» илкүләм проектына керә торган «Чиста ил» федераль проекты чараларын, шул исәптән «Чиста ил» федераль проекты кысаларында әйләнә-тирә мохиткә тупланган экологик зыян салуның аеруча куркыныч объектларын һәм шәһәрләр чикләрендәге санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү чараларын тормышка ашыру планлаштырыла.

Өченче бурычны хәл итүнең төп күрсәткечләре түбәндәгеләр:

әйләнә-тирә мохиткә зарарлы тупланган иң куркыныч объектлар саны, данә;

шәһәрләр чикләрендә ликвидацияләнгән санкцияләнмәгән чүплекләр саны, данә;

2018 елның 1 гыйнварына ачыкланган шәһәрләр чикләрендә санкцияләнмәгән чүп-чар өемнәрен һәм тупланган экологик зыянның иң куркыныч объектларын бетерүгә бәйле рәвештә тормыш сыйфаты яхшырачак халык саны, мең кеше;

әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән Россия Федерациясе милкендәге тупланган зыянлы аеруча куркыныч булган объектлар бетерелүгә бәйле рәвештә тормыш сыйфаты яхшырачак халык саны, мең кеше;

шәһәрләр чикләрендә санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерүгә бәйле рәвештә тормыш сыйфаты яхшырачак халык саны, мең кеше;

әйләнә-тирә мохиткә җыелган зыянның тискәре йогынтысына дучар ителгән торгызылган, шул исәптән рекультивацияләнгән, җирләрнең гомуми мәйданы, гектар.

Дүртенче бурыч кысаларында «Экология» илкүләм проектына керә торган «Иделне савыктыру» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында Идел елгасына куркыныч яный торган үткәндәге экологик зыян объектларын бетерү карала.

Дүртенче бурычны хәл итүнең төп күрсәткече булып Идел елгасына куркыныч янаучы экологик зыянның бетерелгән объектлары саны тора, берәмлек.

Бишенче бурыч кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү каралган.

Бишенче бурычны хәл итүнең төп күрсәткече булып радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу берәмлекләре белән алынган хисаплар санының гомуми санына карата нисбәте тора, процент.

2 нче ярдәмче программа максаты, бурычлары һәм чаралары яктылыгында 2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турында җентекле мәгълүмат 2 нче ярдәмче программага 1, 2 нче кушымталарда китерелә.

2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру сроклары: 2 этапта 2014 – 2024 еллар. I этап: 2014 – 2019 еллар, II этап: 2020 – 2024 еллар.»;

2 ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 2 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү күләме 9 753 986,8 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән 2 672 281,1 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 7 081 705,7 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелә торган федераль бюджет акчасы, шул исәптән:

(мең сум)

| Еллар | Барлыгы* | Федераль бюджет акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 164 187,8 | - | 164 187,8 |
| 2015 | 128 940,8 | - | 128 940,8 |
| 2016 | 26 902,2 | - | 26 902,2 |
| 2017 | 91 627,5 | 26 866,0 | 64 761,5 |
| 2018 | 91 059,8 | - | 91 059,8 |
| 2019 | 12 335,8 | - | 12 335,8 |
| Барысы I этап | 515 053,9 | 26 866,0 | 488 187,9 |
| 2020 | 1 113 805,9 | 718 084,2 | 395 721,7 |
| 2021 | 1 138 456,9 | 804 801,1 | 333 655,8 |
| 2022 | 3 501 782,9 | 2 793 659,9 | 708 123,0 |
| 2023 | 1 727 955,3 | 1 326 143,8 | 401 811,5 |
| 2024 | 1 756 931,9 | 1 412 150,7 | 344 781,2 |
| Барысы II этап | 9 238 932,9 | 7 054 839,7 | 2 184 093,2 |
| Барлыгы | 9 753 986,8 | 7 081 705,7 | 2 672 281,1 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

2 ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. 2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

2 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру белщн идарә итү системасы күз алдында тота:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының муниципаль районнар (шәһәр округлары) башкарма комитетлары, коммуналь комплекс оешмалары - Татарстан Республикасы ККК белән эш итү буенча тцбщк операторларын, 2 нче ярдәмче программа чараларын башкаручылар белән эш итү (ККК белән эш итү эшчәнлеген оештыру буенча төзелүче килешүләр кысаларында һәм ККК белән эш итүнең коммуналь инфраструктурасы объектларын төзүгә карата концессия килешүләре кысаларында);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2 нче ярдәмче программаның дәүләт заказчылары белән үзара хезмәттәшлеге, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын юкка чыгару өлешендә 2 ярдәмче программа чараларын үтәү буенча әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә

идарәгә дәүләт заказын үтәү.

2 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр), Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә төзелгән Россия Федерациясе бюджетыннан субсидия бирү турында килешүләр, Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы территориясендә 2 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты белән Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы арасында Татарстан Республикасы бюджетыннан табигатьне саклау чараларын үтәүгә субсидияләр бирү турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

2 нче ярдәмче программаның дәүләт заказчылары

чираттагы финанс елына бүлеп бирелгән финанс чараларын исәпкә алып, чараларны гамәлгә ашыра, ел саен максатчан индикаторларга ирешүне, программа чараларын гамәлгә ашыруга киткән чыгымнарны, ярдәмче программаларны гамәлгә ашыру механизмын һәм аны башкаручылар составын ачыклыйлар;

Программа буенча хисаплылыкны билгеләнгән тәртиптә тапшыру кысаларында финанс чараларыннан файдалануның 3 нче ярдәмче программасын гамәлгә ашыру барышы һәм нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат җибәрәләр;

2 нче ярдәмче программаның төп чараларын үтәүчеләр 2 нче ярдәмче программа чараларының үтәлеше, бүлеп бирелә торган финанс чараларының рациональ файдалануы өчен җавап бирә.»;

2 ярдәмче программаның V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

### «V. 2 нче ярдәмче программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру 2024 елга түбәндәге нәтиҗәләрне алуны тәэмин итәчәк.

Җитештерү һәм куллану калдыкларын зарарсызландыру һәм күмү аларны булдыруны һәм алардан файдалануны минимальләштерү өстенлеге төбәк халкының социаль һәм икътисадый мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк, шул исәптән:

идарәнең төрле баскычларында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру өчен норматив хокукый һәм технологик база булдырырга;

Татарстан Республикасының каты коммуналь һәм сәнәгать калдыклары полигоннарында урнашкан калдыклар күләмен зональ принцип буенча оештырыла торган һәм калдыкларны автоматлаштырылган сортларга аеру һәм эшкәртү буенча җитештерү куәтләрен, шулай ук таләп ителә торган логистик инфраструктураны, калдыкларны эшкәртүнең инновацион технологияләрен гамәлгә кертү исәбенә

калдыклар белән идарә итүнең комплекслы системаларын төзү исәбенә киметергә;

экологик товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базарын үстерергә, җитештерү һәм куллану калдыкларын утильләштерү һәм икенчел куллану индустриясен формалаштыру өчен шартлар тудырырга, шул исәптән җылылык һәм электр энергиясе алу максатларында калдыклардан файдалануга;

җитештерү һәм куллану калдыкларының сортлаштырганнан һәм эшкәрткәннән соң күмүгә җибәрелә торган уртача масса өлешен киметергә һәм шуңа бәйле рәвештә ККК полигоны өчен яңа мәйданнар даими бүлеп чыгару кирәклеген бетерергә;

ККК санкцияләнмәгән чүплекләрен юк итәргә;

калдыкларны урнаштыруның яңа объектлары өчен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән җирләрне сәнәгать җирләренә бүлеп бирү зарурлыгын төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алуны һәм тикшереп торуны тәэмин итәргә;

әйләнә-тирә мохитнең торышын яхшыртырга, узган һәм агымдагы хуҗалык эшчәнлегенә бәйле экологик куркынычларны киметергә;

җыелган экологик зыян факторлары йогынтысында имин булмаган экологик яшәү шартлары китереп чыгарган халыкның авыруларын киметергә, уртача гомер озынлыгын арттырырга;

